РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА МОНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423644, Менделеевский район, с. Монашево
ул. Школьная, д 19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МОНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
423643, Менделеевск районы, Монаш авылы, Мәктәп урамы, 19

Тел. (факс): (85549) 3-73-18 e-mail: Mon.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 6 декабреннән №3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Актаҗик авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 19 декабре 16 сәгатькә Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең Актаҗик авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп Актаҗик авылы, Левовозжайская урамы, 13 йорт адресы буенча урнашкан Монаш авыл мәдәният йортын билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

1. «Менделеевск муниципаль районының Монаш авыл җирлегенең Актаҗик авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, Россия Армиясендә ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан, көндезге укуда булган студентлардан 500 сум, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә хәрби хезмәткә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, I һәм II төркем инвалидларны түләүдән азат итеп, үзара салым кертүгә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә ризалыгыгыз бармы?:
2. Чүп баклары сатып алу
3. Правовозжайская һәм Левовозжайская урамнарыда юлларга таш җәю

“РИЗА” «КАРШЫ»

3.5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән

игълан итәргә һәм  Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында  www.mendsleevsk.tatar.ru. бастырып чыгарырга

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Монаш авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов